КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 14 март г.Казань № 151

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казансу елгасы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле чикләре урнашу урынының график тасвирламасын раслау турында» 2023 ел, 2 февраль, 84 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Казансу елгасы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле турындагы нигезләмәне раслау хакында;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

«Казансу елгасы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле турындагы нигезләмәне;

«Казансу елгасы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле чикләре урнашу урынының график тасвирламасын.»;

2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карарга «Казансу елгасы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле турындагы нигезләмәне (карарга теркәлә) өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәлләре турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2019 ел, 29 март, 237 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 13 июль, 579 нчы; 2021 ел, 21 май, 352 нче; 2022 ел, 22 февраль, 152 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Саклана торган объектлары елгалар булган төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәлләре турындагы нигезләмәгә кушымтаның 12 пункты үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 2 февраль, 84 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 14 март, 151 нче
карары редакциясендә)

# «Казансу елгасы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Казансу елгасы» төбәк әһәмиятендәге табигать һәйкәле (алга таба – табигать һәйкәле) – экологик чылбырда иң мөһим звено буларак елгаларны саклап калу максаты белән оештырылган төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территориясе.

Табигать һәйкәле Арча, Биектау муниципаль районнары һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан, аның озынлыгы – 154 километр.

1.2. Табигать һәйкәле Татарстан Республикасының табигать-тыюлык фонды составына керә.

Табигать һәйкәленең чикләре җирлектә махсус мәгълүмат билгеләре белән билгеләнә.

1.3. Табигать һәйкәле Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) карамагында тора.

1.4. Табигать һәйкәле милекчеләрдән, җирдән файдаланучылардан, җир хуҗаларыннан һәм арендага алучылардан кишәрлекләрне алмыйча булдырыла.

1.5. Табигать һәйкәленең чикләре һәм махсус саклау режимы үзенчәлекләре территориаль планлаштыру документларын әзерләгәндә, урман хуҗалыгы регламентларын һәм урманнарны үзләштерү проектларын эшләгәндә, урман корылышы эшчәнлеген башкарганда һәм җирләрне инвентаризацияләгәндә исәпкә алына.

## II. Табигать һәйкәленең махсус саклау режимы

2.1. Табигать һәйкәле территориясендә табигать комплексларына тискәре (зарарлы) йогынты ясый торган теләсә нинди эшчәнлек тыела, шул исәптән:

җир кишәрлекләре бирү һәм аларны булдыру;

биналар, төзелмәләр һәм башка корылмалар төзү (әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктындагы икенче абзацында каралган мондый төзелеш очрагыннан тыш);

агызыла торган суларны, шул исәптән дренаж суларын агызу;

гидрологик режимны үзгәртү;

әгәр табигать һәйкәленең табигать комплексларына зыян китерсә, су ресурсларын эксплуатацияләү;

калдыкларның барлык төрләрен урнаштыру, җир өсте суларын пычрату;

материалларны, грунтларны, карны оеп кую;

файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару, файдалы казылмалар ятмаларын эзләүне һәм бәяләүне үз эченә алган геологик өйрәнү, шулай ук җир асты байлыклары кишәрлекләренең файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен яраклылыгын геологик өйрәнү һәм бәяләү;

агачларны, куакларны кисү һәм (яисә) үсемлекләр капламын бозу (урманнарны янгынга каршы төзекләндерү; урманнарны саклау, яклау һәм яңадан торгызу; табигать комплексларын һәм табигать һәйкәле объектларын саклау һәм торгызу максатларында; гражданнар иминлеген тәэмин итү, линия объектларын эксплуатацияләү куркынычсызлыгы буенча, шул исәптән аларның саклау зоналары киңлеген саклау буенча чараларын уздыру очракларыннан тыш; шулай ук линия объектларына техник хезмәт күрсәтү кысаларында реконструкцияләгәндә, капиталь ремонтлаганда, ремонтлаганда һәм яңа линия объектларын төзегәндә);

сәнәгать балыкчылыгы;

су объекты ярларында автотранспорт чараларын һәм авыл хуҗалыгы техникасын юу;

табигать һәйкәле территориясенә турыдан-туры чыга торган җәйге терлек лагерьлары төзү;

махсус билгеләнгән урыннардан тыш, терлекләрне куалап күчерү;

хайваннарның ояларын, өннәрен, башка яшәү урыннарын бетерү, шулай ук кыргый хайваннарны борчуга китерә торган башка гамәлләр кылу;

яшәү тирәлегеннән алып, хайваннар дөньясы объектларыннан файдалану, шулай ук хайваннар дөньясы объектларына зыян китерү (хайваннар дөньясы объектларын фәнни максатларда, фәнни-тикшеренү һәм контрольдә тоту, һәвәскәр һәм спорт аучылыгы максатларында максатларында балык тотудан, аларның санын җайга салу, шулай ук сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган хайваннар дөньясы объектларының популяцияләрен торгызу буенча чараларны гамәлгә ашырудан тыш);

промысел аучылыгы;

киртәләргә, аншлагларга, шлагбаумнарга, стендларга, чик баганаларына, күрсәткечләргә һәм башка мәгълүмат билгеләренә, эшләнгән экологик сукмакларга, төзелмәләргә һәм корылмаларга зыян салу, агачларга язулар һәм билгеләр төшерү;

Зур Зәңгәр күлдән (географик координатлары 55.900299, 49.156193; 55.900106, 49.156735) Кече Зәңгәр күлгә (географик координаталары 55.915053, 49.182332; 55.914877, 49.183016) кадәр Казансу елгасында, түбәндәгеләрнең азсыешлы үзйөрешле судноларыннан тыш, азсыешлы үзйөрешле суднолар йөрү һәм туктап тору;

махсус сакланыла торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органнарның;

табигать һәйкәле чикләрендә вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган башка дәүләт һәм муниципаль органнарның;

линия объектларына һәм инженерлык-техник коммуникацияләргә хезмәт күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру, фәнни тикшеренүләрне үткәрү, шулай ук аварияләрне, табигый бәла-казаларны һәм гадәттән тыш характердагы башка хәлләрне бетерү чараларын үткәрү өчен файдаланыла торган;

шартнамәләр нигезендә табигать һәйкәле территориясендә хезмәт күрсәтүче юридик затларның, индивидуаль эшмәкәрләрнең;

табигать һәйкәлендә табигать комплексларының экологик тигезлеген боза торган, табигать һәйкәле территориясенең экологик кыйммәтен киметә яки хайваннар һәм үсемлекләр дөньясының саклана торган объектларына һәм аларның яшәү тирәлегенә зыян китерә торган башка эшчәнлек төрләре.

2.2. Табигать һәйкәле территориясендә, Комитет белән килештереп, түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

табигать һәйкәлен булдыру максатларына ирешүгә һәм аның төп бурычларын хәл итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән объектларны төзү һәм реконструкцияләү; табигать һәйкәле чикләреннән читтә урнаштыру вариантлары булмаган очракта, яңа капиталь төзелеш объектлары, гидротехника корылмалары, инженерлык-техник коммуникацияләр, линия объектлары төзү; капиталь төзелеш объектларын, гидротехник корылмаларны, инженерлык һәм техник коммуникацияләрне һәм линия объектларын реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм әлеграк төзелгәннәрне ремонтлау;

терлекләрне куалап күчерү өчен урыннар билгеләү;

табигать һәйкәле кишәрлекләрендә экологик реабилитация үткәрү;

үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларының, шул исәптән Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән төрләрнең яшәү тирәлеге шартларын яхшыртуга ярдәм итә торган профилактика чараларын үткәрү;

су объектларының яр буе яклау полосалары чикләрендә һәм хайваннар дөньясы объектларының яшәү тирәлеге буларак аеруча кыйммәтле булган кишәрлекләрдә камыш әзерләү һәм чабу;

биотөрлелекне, табигать объектларын һәм комплексларны өйрәнүгә һәм торгызуга юнәлдерелгән фәнни тикшеренүләр үткәрү, шулай ук археологик мирас объектларын ачыклау, өйрәнү һәм саклау максаты белән археологик эшләрен башкару;

экологик туризмны гамәлгә ашыру;

төбәк геологиясен өйрәнү.

2.3. Табигать һәйкәле территориясендә хуҗалык эшчәнлеге бу Нигезләмәгә һәм җитештерү процессларын гамәлгә ашырганда, шулай ук «Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы нигезендә расланган транспорт магистральләрен, торба үткәргечләрне, элемтә һәм электр тапшыру линияләрен эксплуатацияләгәндә хайваннар дөньясы объектларының һәлак булуын булдырмау таләпләренә таянып гамәлгә ашырыла.

## III. Җир кишәрлекләреннән
## рөхсәт ителгән файдалану төрләре

3.1. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2020 елның 10 ноябрендәге П/0412 номерлы боерыгы нигезендә табигать һәйкәле чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалануның түбәндәге төп төрләре, әгәр алар бу Нигезләмәнең II бүлегендәге таләпләренә каршы килмәсә, рөхсәт ителә:

табигать-танып белү туризмы (Дәүләт комитеты белән килештереп) (5.2*);

табигать территорияләрен саклау (9.1*);

тарихи-мәдәни эшчәнлек (Дәүләт комитеты белән килештереп) (9.3*);

су объектларыннан гомуми файдалану (Дәүләт комитеты белән килештереп) (11.1*);

су объектларыннан махсус файдалану (Дәүләт комитеты белән килештереп) (11.2*);

гидротехника корылмасы (Дәүләт комитеты белән килештереп) (11.3*);

элемтә (Дәүләт комитеты белән килештереп) (6.8*);

торба үткәргеч транспорт (Дәүләт комитеты белән килештереп) (7.5*).

## IV. Табигать һәйкәле территориясендә
## капиталь төзелеш объектларының рөхсәт ителгән төзелешенең,
## реконструкциясенең иң чик максималь параметрлары

4.1. Табигать һәйкәле территориясендә капиталь төзелеш объектларының рөхсәт ителгән төзелешенең, реконструкциясенең иң чик максималь параметрлары: җир кишәрлеге чикләрендә төзелеш проценты – иң күбе 10 процент.

_______________

*Код билгеләнеше Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2020 елның 10 ноябрендәге П/0412 номерлы боерыгы белән расланган җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторы буенча.